ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www.agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30»декабрь 2019ел № 502

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының 2015 елның 13 мартындагы
125 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районында финанс-бюджет өлкәсендә
контроль вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт (муниципаль) финанс контролен, эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын камилләштерү өлешендә Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 26 июлендәге 199-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Муниципаль финанс-бюджет контролен гамәлгә ашыру мәсьәләләрен җайга сала торган законнардагы үзгәрешләр турында» 2019 елның 12 ноябрендәге 02-01-05-2019 Татарстан Республикасы Әгерҗе районы прокуратурасының мәгълүматы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 13 мартындагы 125 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында финанс-бюджет өлкәсендә контроль вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

7 пунктның е пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«е) юридик затлар (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән, дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, дәүләт корпорацияләреннән (компанияләрдән), гавами-хокук компанияләреннән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм аларның устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләре катнашында җәмгыятьләр, шулай ук мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләрнең өлеше (кертеме) булган коммерция оешмаларыннан тыш), түбәндә санап үтелгән шәхси эшмәкәрләр, физик затлар:

тиешле бюджеттан һәм (яисә) дәүләт (муниципаль) контрактлар нигезендә акча бирү турындагы шартнамәләр (килешүләр) нигезендә тиешле бюджеттан акча, Дәүләт һәм муниципаль гарантияләр белән тәэмин ителгән кредитлар алучы юридик һәм физик затлар, шәхси эшмәкәрләр;

федераль законнар нигезендә Федераль казначылыкта, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының финанс органында шәхси счетлар ачылган тиешле бюджеттан һәм (яисә) дәүләт (муниципаль) контрактлардан акча бирү турындагы

шартнамәләрне (килешүләрне) үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча эш башкаручылар (тәэмин итүчеләр, подрядчылар);».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Баженовага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.С. Авдеев**